**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Фосфорорганик химия өлкәсендә халыкара Арбузов премиясен гамәлгә кую турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Фосфорорганик химия өлкәсендә халыкара Арбузов премиясен гамәлгә кую турында» 1997 елның 11 июлендәге ПУ-359 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2006 елның 18 августындагы ПУ-313 номерлы, 2017 елның 8 апрелендәге ПУ-297 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 11 июлендәге 484 номерлы һәм 2024 елның 5 августындагы 592 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Фосфорорганик химия өлкәсендә халыкара Арбузов премиясе турындагы нигезләмәгә:

1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Фосфорорганик химия өлкәсендә халыкара Арбузов премиясе (алга таба шулай ук – Халыкара Арбузов премиясе) галимнәрне фосфорорганик химия өлкәсендә күренекле фәнни хезмәтләре, фәнни ачышлары һәм уйлап-табулары өчен бүләкләү һәм академиклар А.Е. Арбузов һәм Б.А. Арбузов турында хәтерне мәңгеләштерү максатында гамәлгә куелды.»;

4 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Кандидатлар Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Фосфорорганик химия өлкәсендә Халыкара Арбузов премиясен бирү комитеты (алга таба – Комитет) тарафыннан, аларның хезмәтләренең, ачышларының һәм уйлап табуларының фәнни һәм гамәли кыйммәтен исәпкә алып, сайлап алына. Премия бирү турында тәкъдимнәрне дәүләт хакимияте органнары, Россия, чит ил һәм халыкара фәнни оешмалар, югары белем бирү мәгариф оешмалары һәм башка оешмалар, Халыкара Арбузов премиясе лауреатлары кертә ала.»;

б) Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Фосфорорганик химия өлкәсендә халыкара Арбузов премиясен бирү Комитеты турында нигезләмәдә:

2 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Комитет тарафыннан расланган регламент нигезендә, аларның хезмәтләренең, ачышларының һәм уйлап табуларының фәнни һәм гамәли

кыйммәтләрен исәпкә алып, Фосфорорганик химия өлкәсендә халыкара Арбузов премиясен бирүгә кандидатлар сайлап алу;»;

4 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Комитет фәнни хезмәтләрне, фәнни ачышларны һәм уйлап табуларны рецензияләү һәм аларга экспертиза ясау өчен фосфорорганик химия өлкәсендә аерым белгечләрне, шулай ук фәнни-тикшеренү оешмаларын, югары белем бирү мәгариф оешмаларын һәм башка оешмаларны җәлеп итәргә хокуклы.».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ

Казан, Кремль
2025 ел, 06 март
№ 183